ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

21.11.2025 ел № 4

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Маҗын авыл җирлегенең Яңа Маҗын торак пунктында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

Россия Федерациясенең 2025 елның 20 мартындагы № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законының 45 нче, 69 нчы статьялары нигезендә, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге № 45-ЗРТ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Законының 35 нче статьясы, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Яңа Маҗын авыл җирлеге башлыгының 31.10.2025 ел № 16 карары нигезендә, 2026 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Яңа Маҗын авыл җирлегенең Яңа Маҗын торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Яңа Маҗын авыл җирлеге Яңа Маҗын торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә (1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, СВОда катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, СВОда катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан, Чернобыль АЭСында ликвидациядә катнашучылардан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш).

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Яңа Маҗын торак пунктында тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (урам өчен светодиод яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) ремонтлау;

2) Яңа Маҗын торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (ком-таш катнашмасы белән сипләү, урамнар буенча юлны ремонтлау: Луговая, Коммунистическая, Молодежная урамнарында килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

Халык җыены нәтиҗәләрен Яңа Мажын авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Минзәлә муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән http://menzelinsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә халыкка игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
ТР Минзәлә муниципаль районы
Яңа Мажын авыл җирлеге башлыгы _____ И.А.Колбин